**Республика Татарстан**
**Совет**
**Азалаковского сельского**
**поселения Сармановского**
**муниципального района.**
423371 с. Азалаково ул Зеленая дом 4
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Азалак авыл жирлеге**
**Советы.**
423371 Азалак авылы Яшеллек урамы
4 йорт.

ОГРН 1021601313381, ОКПО 93068255, ОКАТО 92253804000,
ИНН/ КПП 1636001386/163601001,ОКТМО 92653404

---

РЕШЕНИЕ КАРАР
24.09.2018 ел. № 17

Азалак авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Азалак авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советының «референдум үткәрү инициативасы турында» 17.09.2018 ел, № 15 карары нигезендә Азалак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 2018 елның 18 ноябренә Азалак авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, тыл хезмәтчәннәре, көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2019 елда 200 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

1.Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләренраслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шул исәптән:

- Азалак, Шыгай, Юлтимер авылларында урамнарны яктырту объектларын ремонтлау һәм карап тоту, урам утының өстәмә нокталарын, таймерларны урнаштыру, лампаларны энергияне сак тотучы лампаларга алмаштыру;
- Шыгай авылы мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм һәйкәл тирәсенә брусчатка җәю;
- Азалак авылының Яшел урамындагы вак агачларны кисү;

- төзекләндерү эшләре буенча эшчеләрнең хезмәтләре өчен түләү (территорияне чистарту, үлән чабу өчен);
-Газель-САЗ -3512 махсус техника өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.
2. Җирлек халкын ял иттерүне оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән:
- Азалак, Шыгай, Юлтимер авылларында «Сабантуй» бәйрәме һәм мәдәни чаралар үткәрү өчен бүләкләр алу.
3. Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар белән тәэмин итү, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрү, шул исәптән:
- Азалак, Юлтимер, Шыгай авылларында спорт чаралары өчен спорт инвентаре һәм бүләкләр сатып алу.
4. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын тоту, шул исәптән:
- Шыгай авылы зираты өчен генератор сатып алу;
- Азалак авылы зираты өчен эретеп ябыштыру аппараты сатып алу;
- некрологларны район «Сарман " газетасында бастырып чыгару.
5. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген алып бару, шул исәптән:
- Азалак авылында Речная, Шыгай авылында Набережная, Юлтимер авылында Горная, Молодежная, Новая урамнары юлларына ремонт үткәрү һәм вак таш катламы җәю?”

әйе юк?».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Совет Рәисе: И.Г.Габдулгазизов